**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об утверждении Правил приглашения и отбора независимых экспертов, включаемых в составы конкурсных и аттестационных комиссий государственных органов Республики Татарстан

В соответствии с частью $8^2$ статьи 22 и частью $10^2$ статьи 48 Федерального закона от 27 июля 2004 года № 79-ФЗ «О государственной гражданской службе Российской Федерации», частью $10^2$ статьи 21 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан», а также с учетом постановления Правительства Российской Федерации от 12 марта 2021 года № 359 «Об утверждении Правил приглашения и отбора независимых экспертов, включаемых в составы конкурсных и аттестационных комиссий федеральных государственных органов» **постановляю**:

1. Утвердить прилагаемые Правила приглашения и отбора независимых экспертов, включаемых в составы конкурсных и аттестационных комиссий государственных органов Республики Татарстан.

2. Департаменту государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан организовать работу по приглашению и отбору независимых экспертов, включаемых в составы конкурсных и аттестационных комиссий государственных органов Республики Татарстан.

3. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Руководителя Аппарата Президента Республики Татарстан.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
30 июня 2021 года
№ УП-529

Утверждены
Указом Президента
Республики Татарстан
от «30» июня 2021 года
№ УП-529

# ПРАВИЛА
## приглашения и отбора независимых экспертов, включаемых в составы конкурсных и аттестационных комиссий государственных органов Республики Татарстан

1. Настоящие Правила устанавливают порядок приглашения и отбора Департаментом государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан (далее – Департамент) независимых экспертов, включаемых в составы конкурсных и аттестационных комиссий, образуемых в государственных органах Республики Татарстан (далее – комиссии), из числа представителей научных, образовательных и других организаций, являющихся специалистами в соответствующих областях и видах профессиональной служебной деятельности государственных гражданских служащих Республики Татарстан, по вопросам кадровых технологий и государственной гражданской службы Республики Татарстан (далее – независимые эксперты).

2. Независимыми экспертами могут быть граждане Российской Федерации, имеющие высшее образование и, как правило, не менее 4 лет стажа работы в областях и видах профессиональной служебной деятельности государственных гражданских служащих Республики Татарстан, по вопросам кадровых технологий и государственной гражданской службы Республики Татарстан.

3. Департаментом из числа граждан, указанных в пункте 2 настоящих Правил, осуществляется формирование и ведение реестра независимых экспертов, рекомендуемых для включения в составы конкурсных и аттестационных комиссий государственных органов Республики Татарстан (далее – реестр).

Реестр ведется по форме, утверждаемой Департаментом, в государственной информационной системе Республики Татарстан «Единая информационная система кадрового состава государственной гражданской службы Республики Татарстан и муниципальной службы в Республике Татарстан».

4. Для формирования и обновления реестра Департамент приглашает независимых экспертов посредством направления запросов о представлении кандидатур независимых экспертов в научные, образовательные и другие организации (далее – организации) и (или) государственные органы Республики Татарстан (далее – органы).

5. Сведения о кандидатурах независимых экспертов направляются в Департамент по форме согласно приложению к настоящим Правилам в срок, не превышающий 30 календарных дней со дня поступления в организацию или орган запроса, указанного в пункте 4 настоящих Правил.

6. Органы и организации вправе направить предложения о кандидатурах независимых экспертов в Департамент для включения в реестр в инициативном порядке по форме согласно приложению к настоящим Правилам.

7. Не допускается направление сведений о кандидатуре независимого эксперта без его согласия, предусмотренного приложением к настоящим Правилам, а также без согласия руководителя организации, представителем которой будет являться данное лицо.

8. Департаментом осуществляется рассмотрение сведений, указанных в пункте 5 настоящих Правил, в течение 30 календарных дней со дня их поступления.

9. По итогам рассмотрения внесенных кандидатур независимых экспертов Департамент:

включает в реестр сведения о кандидатурах независимых экспертов или не включает их в связи с несоответствием требованиям пунктов 2 и 7 настоящих Правил;

обеспечивает информирование руководителей организаций и органов, которыми были направлены сведения, указанные в пунктах 5 и 6 настоящих Правил, о включении (невключении) независимых экспертов в реестр посредством размещения соответствующих сведений на официальном портале Республики Татарстан в разделе «Государственная гражданская и муниципальная служба».

10. Органы не позднее чем за 45 календарных дней до формирования составов комиссий или изменения их составов, в том числе в связи с истечением 3-летнего срока пребывания независимого эксперта в составе комиссии (комиссий), направляют в Департамент запрос о приглашении независимого эксперта (независимых экспертов), включаемого в состав комиссии (комиссий), с описанием требований к независимому эксперту по областям и видам профессиональной служебной деятельности государственных гражданских служащих Республики Татарстан, вопросам кадровых технологий и государственной гражданской службы Республики Татарстан без указания его персональных данных.

11. Департамент осуществляет отбор независимого эксперта (независимых экспертов), являющегося специалистом в областях и видах профессиональной служебной деятельности государственных гражданских служащих Республики Татарстан, по вопросам кадровых технологий и государственной гражданской службы Республики Татарстан, которые указаны в запросе органа.

По итогам отбора Департамент не позднее 10 календарных дней со дня получения запроса направляет в орган сведения о независимом эксперте (независимых экспертах) с учетом его согласия на включение в состав комиссии либо информирует орган об отсутствии кандидатуры.

12. Органы информируют Департамент, независимого эксперта и организацию, представителем которой является данное лицо, об исключении из состава комиссии (комиссий) независимого эксперта (независимых экспертов) в течение 10 рабочих дней после принятия такого решения.

Департамент в течение 10 рабочих дней со дня получения информации об исключении независимого эксперта из состава комиссии (комиссий) обеспечивает внесение изменений в реестр.

13. Организации информируют Департамент об отзыве лица, рекомендованного для включения в состав комиссии (комиссий) в качестве независимого эксперта, в случае принятия такого решения руководителем организации, представителем которой является данное лицо, с обоснованием такого отзыва.

Департамент в течение 10 рабочих дней со дня получения информации об отзыве независимого эксперта уведомляет об этом орган, в состав комиссии (комиссий) которого включен независимый эксперт, и вносит соответствующие изменения в реестр.

14. С согласия независимого эксперта допускается его пребывание в составе комиссии (комиссий) после увольнения из организации, представителем которой является данное лицо, в пределах 3-летнего срока с момента первого включения указанного независимого эксперта в состав комиссии (комиссий).

15. Повторное включение независимого эксперта в состав комиссии (комиссий) может быть осуществлено не ранее чем через 3 года после окончания срока пребывания в соответствующей комиссии (комиссиях).

Приложение
к Правилам приглашения и отбора независимых экспертов, включаемых в составы конкурсных и аттестационных комиссий государственных органов Республики Татарстан

(форма)

**СВЕДЕНИЯ**
**о кандидатуре независимого эксперта, включаемого в составы конкурсной и (или) аттестационной комиссий государственного органа Республики Татарстан**

______________________________________________
(фамилия, имя и отчество (при наличии))

1. Дата рождения ______________________________

2. Сведения об образовании ______________________________

______________________________________________
(направление подготовки (специальность), квалификация)

______________________________________________
(наименование образовательной организации, год окончания)

3. Сведения об участии в конкурсных и (или) аттестационных комиссиях государственных органов Республики Татарстан, органов местного самоуправления, организаций с указанием срока

______________________________________________

______________________________________________

4. Место работы на дату подачи настоящих сведений

______________________________________________

5. Сведения о наличии, как правило, не менее 4 лет стажа работы в областях и видах профессиональной служебной деятельности государственных гражданских служащих Республики Татарстан, по вопросам кадровых технологий и государственной гражданской службы Республики Татарстан

| Месяц и год | | Должность с указанием организации | Области и виды профессиональной служебной деятельности государственных гражданских служащих Республики Татарстан, вопросы кадровых технологий и государственной гражданской службы Республики Татарстан |
|---|---|---|---|
| поступления | ухода | | |
| | | | |

6. Номер мобильного телефона, адрес электронной почты

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

7. Наименования государственных органов Республики Татарстан, в составах конкурсных и (или) аттестационных комиссий которых независимый эксперт готов принимать участие без предварительного согласования

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

Подтверждаю свою готовность к участию в работе конкурсных и аттестационных комиссий государственных органов Республики Татарстан, достоверность и полноту настоящих сведений и свое согласие на их внесение в реестр независимых экспертов, рекомендуемых для включения в составы конкурсных и аттестационных комиссий государственных органов Республики Татарстан, на проведение в отношении меня проверочных мероприятий и обработку моих персональных данных (в том числе автоматизированную обработку) лицами, имеющими доступ к указанному реестру, а также выражаю свое согласие на размещение моих персональных данных (фамилия, имя, отчество (при наличии), должность) на официальном портале Республики Татарстан в разделе «Государственная гражданская и муниципальная служба».

| | |
|---|---|
| ______________________<br>(подпись) | ______________________________<br>(фамилия, имя и отчество (при наличии) лица, рекомендованного в качестве независимого эксперта – представителя организации) |
| «____» ________________ 20___ г. | |
| ______________________<br>(подпись) | ______________________________<br>(должность, фамилия, имя и отчество (при наличии) руководителя организации, представителем которой будет являться независимый эксперт, согласовавшего кандидатуру) |
| «____» ________________ 20___ г. | |

________________

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт органнарының конкурс һәм аттестация комиссияләре составына кертелә торган бәйсез экспертларны чакыру һәм сайлап алу кагыйдәләрен раслау турында**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясындагы $8^2$ өлеше һәм 48 статьясындагы $10^2$ өлеше, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясындагы $10^2$ өлеше нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт органнарының конкурс һәм аттестация комиссияләре составына кертелә торган бәйсез экспертларны чакыру һәм сайлап алу кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 12 мартындагы 359 номерлы карарын исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы дәүләт органнарының конкурс һәм аттестация комиссияләре составына кертелә торган бәйсез экспертларны чакыру һәм сайлап алу кагыйдәләрен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына Татарстан Республикасы дәүләт органнарының конкурс һәм аттестация комиссияләре составына кертелә торган бәйсез экспертларны чакыру һәм сайлап алу эшен оештырырга.

3. Әлеге Указның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә йөкләргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 30 июнь
№ ПУ-529

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның «30» июнендәге
ПУ-529 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы дәүләт органнарының конкурс һәм аттестация комиссияләре составына кертелә торган бәйсез экспертларны чакыру һәм сайлап алу**
**КАГЫЙДӘЛӘРЕ**

1. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (алга таба – Департамент) тарафыннан фән, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре арасыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәләрендә һәм төрләрендә, кадрлар технологияләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте мәсьәләләре буенча белгеч булган, Татарстан Республикасы дәүләт органнарында төзелә торган конкурс һәм аттестация комиссияләре (алга таба – комиссияләр) составына кертелә торган бәйсез экспертларны (алга таба – бәйсез экспертлар) чакыру һәм сайлап алу тәртибе билгеләнә.

2. Югары белемле һәм, кагыйдә буларак, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәләрендә һәм төрләрендә, кадрлар технологияләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте мәсьәләләре буенча ким дигәндә 4 ел эш стажы булган Россия Федерациясе гражданнары бәйсез эксперт була ала.

3. Департамент тарафыннан әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар арасыннан Татарстан Республикасы дәүләт органнарында төзелә торган конкурс һәм аттестация комиссияләре составына кертергә тәкъдим ителә торган бәйсез экспертлар реестры (алга таба – реестр) формалаштырыла һәм алып барыла.

Реестр Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составы бердәм мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасында Департамент тарафыннан раслана торган формада алып барыла.

4. Реестрны формалаштыру һәм яңарту өчен Департамент бәйсез экспертларны, фән, мәгариф һәм башка оешмаларга (алга таба – оешмалар) һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт органнарына (алга таба – органнар) бәйсез экспертлар кандидатураларын тәкъдим итү турында соратулар җибәреп, чакыра.

5. Бәйсез экспертлар кандидатуралары турында белешмәләр әлеге Кагыйдәләрнең 4 пунктында әйтелгән, әлеге Кагыйдәләргә кушымтада бирелгән форма буенча сорату оешмага яисә органга килгәнгә 30 календарь көн тулганчы Департаментка җибәрелә.

6. Органнар һәм оешмалар бәйсез экспертлар кандидатуралары турындагы тәкъдимнәрен Департаментка үз башлангычлары белән әлеге Кагыйдәләргә кушымтада каралган форма буенча реестрга кертү өчен җибәрергә хокуклы.

7. Бәйсез эксперт турындагы белешмәләрне аның әлеге Кагыйдәләргә кушымтада каралган ризалыгыннан, шулай ук әлеге зат вәкиле булачак оешманың җитәкчесе ризалыгыннан башка җибәрү рөхсәт ителми.

8. Әлеге Кагыйдәләрнең 5 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне Департамент тарафыннан карау алар алынган көннән башлап 30 календарь көн дәвамында башкарыла.

9. Бәйсез экспертларның тәкъдим ителгән кандидатураларын карап тикшерү йомгаклары буенча Департамент:

бәйсез экспертлар кандидатуралары турында белешмәләрне реестрга кертә яисә, аларның әлеге Кагыйдәләрнең 2 һәм 7 пунктларына туры килмәве сәбәпле, реестрга кертми;

әлеге Кагыйдәләрнең 5 һәм 6 пунктларында күрсәтелгән белешмәләрне җибәргән оешмалар һәм органнар җитәкчеләренә бәйсез экспертларның реестрга кертелүе (кертелмәве) турында Татарстан Республикасы рәсми порталындагы «Дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт» бүлегендә тиешле белешмәләр урнаштыру аша мәгълүмат бирүне тәэмин итә.

10. Комиссияләр составын төзегәнче яисә аларның составларын үзгәрткәнче 45 календарь көннән дә соңга калмыйча органнар, шул исәптән бәйсез экспертның комиссия (комиссияләр) составында торуына 3 ел вакыт узу белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәләре һәм төрләре, кадрлар технологияләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте мәсьәләләре буенча таләпләр тасвирламасы белән, шәхси белешмәләрне күрсәтмичә генә, Департаментка комиссия (комиссияләр) составына кертелә торган бәйсез экспертны (бәйсез экспертларны) чакыру турында сорату җибәрә.

11. Департамент Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәләре һәм төрләре, кадрлар технологияләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте мәсьәләләре буенча белгечләр булган, орган соратуында күрсәтелгән бәйсез экспертны (бәйсез экспертларны) сайлап алуны башкара.

Сайлап алу йомгаклары буенча Департамент сорату алынган көннән башлап 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, органга бәйсез эксперт (бәйсез экспертлар) турында, аның комиссия составына кертергә рөхсәтен

исәпкә алып, белешмәләр җибәрә яисә органга кандидатураның булмавы турында мәгълүмат бирә.

12. Органнар Департаментка, бәйсез эксперткa яисә әлеге зат аның вәкиле булган оешмага бәйсез экспертның (бәйсез экспертларның) комиссия (комиссияләр) составыннан чыгарылуы турында мондый карар кабул ителгәннән соң 10 эш көне дәвамында мәгълүмат бирә.

Департамент бәйсез экспертның (бәйсез экспертларның) комиссия (комиссияләр) составыннан чыгарылуы турында мәгълүмат алынган көннән 10 эш көне дәвамында реестрга үзгәрешләр кертүне тәэмин итә.

13. Оешмалар комиссия (комиссияләр) составына бәйсез эксперт сыйфатында кертергә тәкъдим ителгән затны, әлеге зат вәкиле булган оешманың җитәкчесе шундый карар кабул иткән очракта, чакыртып алу турында, мондый чакыртып алуны нигезләп, мәгълүмат бирә.

Департамент бәйсез экспертны чакыртып алу турындагы мәгълүмат алынган көннән 10 эш көне дәвамында бәйсез эксперт комиссиясе (комиссияләре) составына кертелгән органга бу турыда хәбәр итә һәм реестрга тиешле үзгәрешләр кертә.

14. Бәйсез экспертның ул үзе вәкиле булган оешмадан эштән киткәннән соң аның ризалыгы белән әлеге бәйсез эксперт беренче тапкыр комиссия (комиссияләр) составына кертелгән вакыттан алып 3 ел эчендә комиссия (комиссияләр) составында калуы рөхсәт ителә.

15. Бәйсез экспертның комиссия (комиссияләр) составына кабаттан кертелүе аның тиешле комиссиядә (комиссияләрдә) тору срогы тәмамланганнан соң 3 елдан да иртәрәк башкарыла алмый.

Татарстан Республикасы дәүләт органнарының конкурс һәм аттестация комиссияләре составына кертелә торган бәйсез экспертларны чакыру һәм сайлап алу кагыйдәләренә
кушымта

(форма)

**Татарстан Республикасы дәүләт органнарының конкурс һәм аттестация комиссияләре составына кертелә торган бәйсез эксперт кандидатурасы турында**
**БЕЛЕШМӘЛӘР**

____________________________________________________________
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта)

1. Туган елы һәм көне ______________________________________
2. Белеме турында белешмәләр ______________________________

____________________________________________________________
(өзерлек юнәлеше (белгечлеге), квалификациясе)

____________________________________________________________
(мәгариф оешмасының атамасы, тәмамлаган елы)

3. Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар конкурс яисә аттестация комиссияләрендә катнашуы турында вакыты күрсәтелгән белешмәләр

____________________________________________________________

____________________________________________________________

4. Әлеге белешмәләр бирелгән вакытта эшләгән урыны

____________________________________________________________

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәләрендә һәм төрләрендә, кадрлар технологияләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте мәсьәләләре буенча, кагыйдә буларак, ким дигәндә 4 ел эш стажы булу турында белешмәләр

| Ай һәм ел | | Оешманы күрсәтеп, вазыйфа | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәләре һәм төрләре, кадрлар технологияләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте мәсьәләләре |
|---|---|---|---|
| эшкә керү | эштән китү | | |
| | | | |

6. Мобиль телефон номеры, электрон почта адресы

___

___

7. Бәйсез эксперт, алдан килештермичә, конкурс һәм (яки) аттестация комиссияләре составында катнашырга әзер булган Татарстан Республикасы дәүләт органнары атамалары

___

___

___

___

___

Үземнең Татарстан Республикасы дәүләт органнарының конкурс һәм аттестация комиссияләре эшендә катнашырга әзерлегемне, әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын һәм аларны Татарстан Республикасы дәүләт органнарының конкурс һәм аттестация комиссияләре составына кертергә тәкъдим ителгән бәйсез экспертлар реестрына кертелүенә, әлеге реестр белән эшләргә хокуклы затларның миңа кагылышлы тикшерү чаралары уздыруына һәм минем шәхси белешмәләремне эшкәртүгә (шул исәптән автоматлаштырылган эшкәртүгә) ризалыгымны раслыйм, шулай ук минем шәхси белешмәләремне (фамилиям, исемем, атамның исемен (булган очракта), вазыйфамны) Татарстан Республикасының рәсми порталында «Дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт» бүлегендә урнаштыруга ризалыгымны белдерәм.

| | |
|---|---|
| ___ (имза) | ___ (оешманың вәкиле – бәйсез эксперт буларак тәкъдим ителгән затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта) |

20___елның «_____» ____________

| | |
|---|---|
| ___ (имза) | ___ (бәйсез эксперт вәкиле булачак оешманың аның кандидатурасын килештергән җитәкчесенең вазыйфасы, фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта) |

20___елның «_____» ____________

___